# Ислам-Нур

ДУХОВНО-ПРОСВЕТИТЕЛЬСКАЯ ГАЗЕТА РЕГИОНАЛЬНОГО
ДУХОВНОГО УПРАВЛЕНИЯ МУСУЛЬМАН
САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ
И САМАРСКОЙ СОБОРНОЙ МЕЧЕТИ

*Самар өлкәсе җирле мөселман дини идарәсе һәм
Самар Җәмигъ мәчетенең
рухи-мәгърифәтчелек басмасы*

«Ләәә иләәһә илләллааһ» догасын кабатлап, искә
төшерүегез белән иманыгызны яңартыгыз һәм куәтләгез

6 +

№ 4 (87), 28 февраль 2013 ел (18 Рабиг әл-ахир 1434 ел)

## Хаҗга тик Самар мөфтияте аша гына барыгыз!

Хаҗ кылу - мөселманнарның изге гамәле.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

“Көче җиткән кешеләргә Аллаһыга гыйбадәт өчен хаҗ кылу фарыздыр”.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.с.) әйткән:

“Ике кече хаҗ кылу арасында кеше барлык гөнаһларыннан котыла, ә зур хаҗ өчен бүләк булып оҗмах тора”.

“Кем хаҗ кылганда сүгенми, гөнаһ кылмый, ул кеше хаҗдан, анасы тудыргандагы кебек, гөнаһсыз булып кайта”.

**Соңгы елларда хаҗ сәфәрен оештыру буенча алдакчы фирмалар барлыкка килде.**

Хаҗ кылучылардан кунакханә бәясен алалар да, яшәүне тулай торакларда (общежитиедә) оештыралар.

Ашаткан ризыклары түләгән акчага туры килми.

Транспорт, медицина хезмәте яман-нан-яман.

Хаҗга барырга ниятегез булса, түбәндәге телефон буенча шалтыратыгыз:

**8 – 927=750 – 11 - 64.**

* * *

## Язылыгыз, укыгыз, куаныгыз!



## Туганнар!

2013 елга “Ислам - Нур” гәҗитәсенә язылмаган булсагыз, үзегез яши торган җирдә почта бүлегенә барып языла-быз.

**Гәҗитәбезнең индексы - 52381.**

“Ислам - Нур” гәҗитәсен даими укып барсагыз, динебез Ислам турында гыйлемегез артыр.

“Ислам - Нур”ны даими укысагыз, татар халкының гореф-гадәтләрен үзләштерерсез.

Балалар тәрбияләүдәге тәҗрибәгез белән “Ислам - Нур”да уртаклашыгыз.

Балалар тәрбияләүдә авырлыклар килеп чыкса, безнең белән киңәшегез.

Әчегезне бушатып хатлар языгыз.

Җавабын гәҗиттә укырсыз.

Гәҗитә битендә язарга лаек дип санаган кешегез булса, шалтыратып әйтегез, телефоннарыбыз: **932-58-67** һәм **8-937=656-76-16.**

“Ислам-Нур”га язылган булсагыз, якыннарыгызны бушлай тәбриклибез.

Адресыбыз: Самар шәһәре,

Стара Загора урамы, йорт саны 54.

Самар Җәмигъ мәсҗиде.

Редакция “Нур” мәдрәсәсе бинасында урнашкан.

Икенче кат, 26нчы һәм 29нчы бүлмәләр.

Сезләрне яратып көтеп калабыз.

* * *

**Ирләребез**

# *Континентара ракеталарга хезмәт күрсәткән офицер*



Мөфти Талип хәзрәт Яруллин
Рушан Мәҗитовка танылык тапшырды

Гаиләдәге чын мөселманлык рухы ул тирәннән, тамырлардан килә. Дингә олы хөрмәт яшәгән гаиләләрдә генә үрнәк булырлык, сокланырлык шәхесләр тәрбияләнә. Әбдерәшит улы Рушан Мәҗитов менә шул токымнан. Аның белән аралашканда ул түбәндәгеләрне сөйләде:

- Тормыш юлында гомерем буена миңа гел яхшы кешеләр генә очрады. Аллага шөкер, шуңа да тормышым уңышлы, яшәвем мәгънәле булды. Безнең гаиләбездә һәрвакыт дингә, гореф-гадәтләргә, телебезгә һәм милләтебезгә карата әби-бабадан, әти-әнидән мирас булып калган олы хөрмәт яшәп килде. Ул безнең йөрәкләребездә кадерләп саклана. Аллага шөкер, без моны балаларыбызга, оныкларыбызга да җиткерә алдык. Шуңа да үземнең һәм аларның тормышындагы уңышларына куанып яшимен, диде ул горурланып.

Әйе, кеше үз гомерендә ни эзләсә - шуны таба. Үзе яхшы булса, яхшылыклар эшләп яшәсә - аңа гел яхшы кешеләр очрый. Усаллык исәпләп, бозык юлда йөргән кеше тирәсендә, әлбәттә, үз ишләре була.

Тормышта уңышларга ирешкән кеше ул бар җирдә кычкырып, мактанып йөрми. Аның уңай тормышы, эшләгән эшләре, изгелекләре үзләре барысын да аңлата. Тик андый кешеләрне безгә күрә һәм хөрмәт итә белергә кирәк.

Әңгәмәдәшебез Рушан хаҗи Мәҗитов дәһшәтле 1941 елның май аенда Ульян өлкәсендәге Иске Кулаткы районының Иске Зеленое авылында туып-үскән. Урта белем алып, армия сафларында хезмәт иткәч, Хабаровск шәһәрендә хәрби училищега укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлый. Аның континентара ракеталар белән бәйләнгән хәрби хезмәте Алтай краенда, Новосибирск һәм Владимир шәһәрләрендә уза. Хезмәттә майор дәрәҗәсенә ирешә һәм командование тарафыннан “За боевые заслуги” медале белән бүләкләнә. Тыныч тормышта бу бик сирәк була торган хәл. Тырыш хезмәте өчен ул ун медальга һәм тагын күп бүләкләргә, мактауларга лаек була. Алар арасында “За доблестный труд”, I, II һәм III дәрәҗәле “За безупречную службу” медальләре дә бар (I, II һәм III дәрәҗәле медальләре барысы бергә орденга тиңләнә).

Хәрби хезмәттән киткәч, Рушан хаҗи Мәҗитов Владимир шәһәрендә яши. Җомга көннәрендә намазга йөри башлый. 1996 елда аны башта кассир, аннан соң мәхәллә рәисе итеп сайлыйлар. Белемле, аралашучан буларак, ул мөселман җәмгыятен юстиция бүлегендә рәсмиләштерү өчен күп көч куя. Шулай итеп, Владимир шәһәрендә һәм өлкәсендә беренче мөселман җәмгыяте рәсми теркәлә, һәм ул бирелдәге дин үсешенә сәбәп була.

Ислам диненә тирән бирелеп, Мәскәү мөфтияте каршындагы мәктәпкә укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлый. Аннан соң Россия президенты администрациясе каршында оештырылган кыска сроклы Дәүләт Академиясе каршындагы курсларда укый һәм аны уңышлы тәмамлый. Аңа Владимир өлкәсе “имам-мөхтәсибе” дәрәҗәсе һәм бу хакта танылык бирелә.

Бирелдә, Рәсәй илендәге христиан диненең рухи мәркәзләреннән саналган Владимир өлкәсендә, Ислам динен күтәреп чыгу - ул бик мәшәкатьле һәм катлаулы эш. Мәчет салу һәм моның өчен җир алу бөтенләй мөмкин булмаган чорда моның бердәнбер юлы ул йорт сатып алу була. Зур кыенлыклар аша Аллаһы Тәгалә ярдәме һәм халыкның тырышлыгы аркасында йорт сатып алына. Аны тәзекләндерүгә Рушан хаҗи Мәҗитов күп көч куя, үз куллары белән тәзекләндерү эшләрен башкара. Әлбәттә, моңа халык та зур ярдәм күрсәтә, кем ничек булдыра ала, шулай булышалар.

Ни әйтсәң дә, эшнең уңышлылыгы - ул башлап йөрүчедән, халыкны ияртүчедән килә. Бу очракта мондый кеше ул Рушан Мәҗитов була. Владимир өлкәсендәге мөселман җәмгыятенең чишмә башы буларак, киләчәктәге уңышлы эшләр нәкъ менә шушы иске йорттан башлана. Тора-бара Владимир шәһәрендә бер катлы агач корылма урынында дүрт катлы бина барлыкка килә. Монда администрация һәм хуҗалык өлеше, намаз заллары, уку-укыту өлеше, ашханә һәм башка бүлекләр җиһазландырылалар. Ахыр чиктә бу мәчет Владимир шәһәренең архитектура ансамблен җанландырып, аны бизәүче матур бинага әверелә.

Рушан хаҗи Мәҗитов - Владимир өлкәсендә беренче булып хаҗ кылган кеше. Аның балалары, оныклары да динне, милләтне хөрмәт итәләр. Бөтен оныклары дин юлында. Алар барысы да туган телебездә, татар телендә аралашалар.

Рушан хаҗи дин белән бергә милләтебез киләчәген дә кайгыртып яши. Ул ике тапкыр Бөтендөнья татар милли конгрессы эшендә катнаша. Конгрессның Башкарма комитеты тарафыннан аның эше югары бәяләнеп, ихтирамнәмә һәм рәхмәт хатлары бирелә. Мөфтиләр шурасының рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин белән тыгыз элемтәдә булып, ул анда тарихка керерлек эшләр башкара.

Рушан хаҗи хәзерге көндә үз токымы белән горурланып, кинәнеп яши. Аның хатыны Гомәр кызы Нурҗиһан хаҗия да бүгенге көндә Мөхәммәдия мәдрәсәсендә белем ала. Алар улларына киленнәрен дә үзләре табып өйләндерәләр. Уллары Илдар да хәрбиләр һөнәрен сайлый. Бүгенге көндә ул полковник дәрәҗәсендә армия командующиеның урынбасары булып хезмәт итә. Ул хәрби училище, аннан соң Академия һәм Генштаб Академиясен тәмамлый. Аның эшчәнлеге хәрби көчләр министрлыгы тарафыннан югары бәяләнә.

Икенче уллары Илгиз - дәрәҗәле табиб. Аның үз поликлиникасы бар. Инде Рушан хаҗиның бер оныгы да хәрби училище тәмамлап, лейтенант булып хезмәт итә башлаган. Алар барысы да хәрбиләр токымыннан. Рушан хаҗиның бабасы да 25 ел Кавказда хәрби хезмәттә булган (әле патша армиясендә).

Рушан хаҗи бүген Сызран шәһәрендә Ислам динен һәм татарларның милли-мәдәни аңын үстерүгә үз өлешен кертә. Яше җитмештән генә узган булуга карамастан, ул төз гәүдәле, җитез хәрәкәтле һәм үз йортында яшәп, актив тормыш алып бара. Ул изге җанлы, киң күңелле, ягымлы һәм шул ук вакытта батыр йөрәкле, туры сүзле шәхес.

Бер мисал: гөрләп эшли башлаган мәчетне ватарга җирле хакимият карар чыгара. Рушан хаҗи хөкүмәт Думасы депутаты аркылы атаклы Ринат Акчурин белән элемтәгә керә һәм аның ярдәмендә президент вәкиле белән очрашып, бу вәхши хәрәкәтне туктата.

Шактый гына дини белем туплаган булса да, Рушан хаҗи бу эшне дәвам итә. Самар шәһәрендәге «Нур» мәдрәсәсендә оештырылган курсларда белемен тагын да камилләштерде ул. (Рәсемдә бу хакта танылык бирү сурәтләнгән).

**Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.**